КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 16 февраль г.Казань № 132

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге концедент булган һәм өченче ягы мәҗбүри тәртиптә Татарстан Республикасы булган җылылык белән тәэмин итү объектларына, кайнар су белән тәэмин итүнең, салкын су белән тәэмин итүнең һәм (яисә) су чыгаруның үзәкләштерелгән системаларына, мондый системаларның аерым объектларына карата концессия килешүләрен әзерләгәндә, төзегәндә, үзгәрткәндә һәм туктатканда Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарының ведомствоара хезмәттәшлек тәртибен раслау турында

«Концессион килешүләр турында» 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру, шулай ук Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарының җылылык белән тәэмин итү объектларына, кайнар су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системаларына, салкын су белән тәэмин итүнең һәм (яисә) су бүлеп бирүнең үзәкләштерелгән системаларына карата концессион килешүләрне әзерләгәндә, төзегәндә, үзгәрткәндә һәм туктатканда үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү һәм координацияләү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Кararга теркәлгән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге концедент булган һәм өченче ягы мәҗбүри тәртиптә Татарстан Республикасы булган җылылык белән тәэмин итү объектларына, кайнар су белән тәэмин итүнең, салкын

су белән тәэмин итүнең һәм (яисә) су чыгаруның үзәкләштерелгән системаларына, мондый системаларның аерым объектларына карата концессия килешүләрен әзерләгәндә, төзегәндә, үзгәрткәндә һәм туктатканда Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарының ведомствоара хезмәттәшлек тәртибен (алга таба - Тәртип) расларга.

2. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына җылылык белән тәэмин итү объектларына, кайнар су белән тәэмин итүнең, салкын су белән тәэмин итүнең һәм (яисә) су чыгаруның үзәкләштерелгән системаларына, мондый системаларның аерым объектларына карата концессион килешүләр әзерләгәндә, төзегәндә, үзгәрткәндә һәм туктатканда Тәртипкә таянып эш итәргә тәкъдим итәргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин